ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 127

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 254 номерлы карары белән расланган архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 472-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Бинаны торак урын дип, торак урынын яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче кушымтадагы «күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокуклар» сүзләрен «күчемсез мөлкәткә» сүзләренә алмаштырырга;

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6. пунктында «төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров